КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 4 февраль г.Казань № 102

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында экологик иминлек, табигатьтән файдалану һәм санитар-эпидемиологик иминлек буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2005 ел, 12 декабрь, 596 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында экологик иминлек, табигатьтән файдалану һәм санитар-эпидемиологик иминлек буенча ведомствоара комиссия составын раслау турында» 2010 ел, 14 декабрь, 1065 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 14 декабрь, 1065 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитария-эпидемиология иминлеге буенча ведомствоара комиссия составына үзгәреш кертү турында» 2011 ел, 21 февраль, 124 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 ел, 12 ноябрь, 851 нче карарының 4 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәренең Мамадыш тракты урамы буйлап Самосырово каты коммуналь калдыклар чүплеген ябуга, алга таба рекультивацияләү белән, әзерлек чаралары комплексы» проектын гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 17 декабрь, 1157 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Этномәдәни һәм тел күптөрлелеген саклап калу һәм аңа булышлык күрсәтү – гомумроссия бердәмлеген ныгытуның иң мөһим факторы» темасына мәдәниятне үстерү мәсьәләләре һәм рухи

мирасны саклап калу буенча Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасының милләтләр һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне гармонизацияләү комиссиясенең уртак утырышын оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау хакында» 2021 ел, 13 ноябрь, 1073 нче карары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин